## ДИАГНОСТИКА

Түбәндәге биремнәрне балаларның татар телен белү дәрәҗәсен билгеләгәндә кулланырга мөмкин. Тикшерү һәр бала белән аерым үткәрелә, ул 5 – 10 минуттан артмаска тиеш. Ә йомгаклау дәресе булганда, тикшерүне барлык балалар белән бергә үткәрергә мөмкин. Биремнәр уен формасында рус телендә аңлатыла. Балаларның җавабын тыңлаганда тикшерүче елмаеп, кирәк булса, җавапны дөресләп, бала әйтә алмаган очракта, булышырга тиеш.

Тикшерү нәтиҗәләрен түбәндәгечә таблицага төшерергә мөмкин.

Нәтиҗәгә карап, тәрбияче, һәр бала белән эшләү өчен, бурычлар билгели.

**Уку елы ахырында уртанчылар, уку елы башында зурлар төркеме балаларының «Минем өем» проекты буенча татар телен үзләштерү дәрәҗәләрен билгеләү**

| № | Балаларның исем, фамилиясе | Сүз байлыгы | | Бәйләнешле сөйләм | | |
|---|---|---|---|---|---|---|
| | | «Минем өем» проекты буенча өйрәнгән лексиканы сөйләмдә куллану. (Өйрәнгән темалар буенча дүрт – биш рәсем яисә предмет күрсәтелә, татарча исемнәрен әйтергә кушыла) | Ягымлы сүзләр куллану («исәнме», «сау бул», «рәхмәт») | Боерыкны аңлап үтәү һәм куллана белү (кил, утыр, сикер, ю, аша, эч) | Тирә-юньдәге предметларның сыйфатын, күләмен белдерә торган сүзләрне аңлап сөйләмдә куллану | Аралаша белү (ягымлы сүзләр әйтү, чакыру, сыйлау, сорап алу, тәкъдим итү, инкарь итү, раслау) |
| 1. | Коля | | | | | |
| 2. | Оля | | | | | |
| 3. | ..... | | | | | |
| 4. | ..... | | | | | |
| **Нәтиҗәләрне билгеләү** | | | | | | |
| *Югары дәрәҗә* 2,7 дән 3 кә кадәр | | Бала сөйләмдә актив, сорауларга җавап бирә, яхшы аралаша. | | | | |
| *Уртача дәрәҗә* 2 дән 2,6 га кадәр | | Сүз байлыгы бар, аралашуда бик үк актив түгел. | | | | |
| *Уртачадан түбән дәрәҗә* 1 дән 2 гә кадәр | | Аңлый, русча җавап бирә. | | | | |